# Словарный минимум УМК по проекту “Минем өем” в средней группе

| | |
|---|---|
| Әти - папа<br>Әни - мама<br>Кыз - девочка<br>Малай - мальчик<br>Әби - бабушка<br>Бабай - дедушка<br>Исәнме - здравствуй<br>Исәнмесез - здравствуйте<br>Сау бул, саубулыгыз - до свидание<br>Эт - собака<br>Песи - кошка<br>Әйе - да<br>Юк - нет<br>Әйбәт - хорошо<br>Ипи - хлеб<br>Алма - яблоко<br>Сөт - молоко<br>Чәй - чай<br>Рәхмәт - спасибо | Мә - на<br>Тәмле - вкусно<br>Кил монда - иди сюда<br>Утыр - садись<br>Бир - дай<br>Аша - кушай<br>Эч - пей<br>Туп - мяч<br>Зур - большой<br>Кечкенә - маленький<br>Матур - красивый<br>Курчак - кукла<br>Куян - заяц<br>Аю - медведь<br>Хәлләр ничек - как дела<br>Уйна - играй<br>Пычрак - грязный<br>Чиста - чистый<br>Ю - мой<br>Бер - один<br>Ике - два<br>Өч - три<br>Дүрт - четыре<br>Биш – пять |

**Пассивные слова**

| | |
|---|---|
| Утырыгыз - садитесь<br>Бу кем? - это кто?<br>Кем юк? - кого нет?<br>Син кем? - ты кто? | Кем анда? - кто там?<br>Басыгыз - встаньте<br>Ал - бери<br>Ничә? - сколько?<br>Нинди? - какой? |

# Словарный минимум УМК по проекту “Уйный-уйный үсәбез” в старшей группе

| | |
|---|---|
| Кишер - морковь<br>Суган - лук<br>Бәрәңге - кортофель<br>Кәбестә - капуста<br>Кыяр - огурец<br>Аш - суп<br>Ботка - каша<br>Баллы - сладкий<br>Кызыл - красный<br>Яшел - зеленый<br>Сары - желтый<br>Зәңгәр - синий<br>Бар - есть<br>Бит - лицо<br>Кул - рука<br>Күлмәк - платье<br>Чалбар - брюки<br>Ки - надень<br>Сал - сними | Алты - шесть<br>Җиде - семь<br>Сигез - восемь<br>Тугыз - девять<br>Ун - десять<br>Нинди? - какой?<br>Ничә? - сколько?<br>Кирәк - надо<br>Нәрсә кирәк? - что надо?<br>Тәлинкә - тарелка<br>Кашык - ложка<br>Чынаяк - чашка<br>Өстәл - стол<br>Урындык - стол<br>Карават - кровать<br>Йокла - спи<br>Бар - есть<br>Юа - моет<br>Яратам – люблю |

**Пассивные слова**

Бу нәрсә? - это что?
Хәерле көн - добрый день
Нәрсә бар? - что есть?

# Словарный минимум УМК по проекту “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” в подготовительной к школе группе

<table>
<tr><td>Син кем? - ты кто?<br>Хәерле көн - добрый день<br>Бу кем? - это кто?<br>Бу нәрсә? - это что?<br>Нишли? - что делает?<br>Нишлисең? - что делаешь?<br>Син нишлисең? - ты что делаешь?<br>Йоклый - спит<br>Утыра - сидит<br>Утырам - сижу<br>Ашый - кушает<br>Ашыйм - кушаю<br>Эчә - пьет<br>Эчәм - пью<br>Уйный - играет<br>Уйныйм - играю<br>Кая барасың? - куда идешь?<br>Барам - иду<br>Сикер - прыгай<br>Сикерәм - прыгаю<br>Сикерә - прыгает<br>Йөгерә - бегает<br>Йөгер - беги<br>Йөгерәм - бегу<br>Җырла - пой<br>Җырлыйм - пою</td><td>Шуа - катается<br>Шуам - катаюсь<br>Бие - пляши<br>Бии - пляшет<br>Бием - пляшу<br>Укый - читает<br>Укыйм - читаю<br>Тычкан - мышка<br>Төлке - лиса<br>Бүре - волк<br>Керпе - еж<br>Тавык - курица<br>Әтәч - петух<br>Үрдәк - утка<br>Чана - санки<br>Дәфтәр - тетрадь<br>Китап укый - книгу читает<br>Укыйм - читаю<br>Рәсем ясыйм - рисую<br>Зур рәхмәт - большое спасибо<br>Чәк-чәк - чак- чак<br>Өчпочмак -триугольник<br>Яшь - молодой<br>Ак - белый<br>Кара - черный</td></tr>
<tr><td colspan="2">Пассивные слова</td></tr>
<tr><td colspan="2">Нәрсә яратасың? - что любишь?</td></tr>
</table>

# НОВЫЕ ПОДХОДЫ В ОБУЧЕНИИ ДЕТЕЙ ДВУМ ГОСУДАРСТВЕННЫМ ЯЗЫКАМ В ДОУ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Модернизация Российского образования внесла конструктивные изменения в систему дошкольного образования. На смену традиционным методам организации педагогического процесса ДОУ пришли технологии личностно-ориентированного взаимодействия педагогов с детьми, целесообразной организации развивающей среды, проектно-деятельностного и компетентностного подходов в организации педагогической работы.

Постановлением кабинета Министров Республики Татарстан от 30.12.2010 г. № 1174 «Об утверждении Стратегии развития образования в Республики Татарстан на 2010-2015 г.г. «Киләчәк», в рамках реализации первоочередных мероприятий Стратегии, творческой группой, созданной Министерством образования и науки Республики Татарстан, **разработан учебно-методический комплект по обучению детей двум государственным языкам в дошкольных образовательных учреждениях Республики Татарстан.**

**Инновация учебно-методического комплекта** в обращении к практике ориентированности, мультимедийности, обучения с помощью игр, сказок, мультфильмов.

**Основная цель учебно-методического комплекта** - формирование правильной устной родной речи детей дошкольного возраста.

**Главной задачей освоения учебно-методического комплекта** является обучение детей правильно и красиво говорить (формирование грамматического строя речи, фонетического и лексического уровней языковой системы, развитии связной речи).

**Учебно-методический комплект** разработан для первой младшей, второй младшей, средней, старшей, подготовительной к школе групп.

**В учебно-методический комплект** вошли:

**I. Материалы для обучения**

1. Рабочие тетради для детей
2. Методические рекомендации и пособия для воспитателей

**II. Материал для формирования языковой среды**

1. Сборники детских художественных произведений для воспитателей и родителей
2. Комплекты аудиоматериалов (песни, танцы)
3. Комплекты видеоматериалов (телепередачи, учебные мультфильмы):
   а) переведенные с русского языка
   б) вновь созданные на татарском языке

**Методические пособия по всем возрастам, имеют обычную структуру**. В пояснительной записке раскрывается актуальность развития речи, обучения детей родному языку. Указаны цель и задачи методического пособия. Дана характеристика структуры методического пособия. Раскрываются возрастные особенности развития детей, которые учитываются при организации воспитательно-образовательного процесса в ДОУ.

# МУЛЬТИМЕДИЙНЫЕ РЕСУРСЫ НОВОГО ПОКОЛЕНИЯ ПО ОБУЧЕНИЮ ДЕТЕЙ ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ

**Специально для обучения детей государственным языкам было разработано:** 11 мультфильмов на татарском языке, 45 анимационных сюжетов, познавательные передачи, которые транслируются на канале ТРК «Новый век».

На канале ТНВ создана телепередача на татарском языке «Әкият илендә» для детей дошкольного возраста в целях обучения детей разговорной речи. Новый проект предоставляет собой возможность совсем юным телезрителям вместе с родителями изучать татарский язык, начиная с самых его азов.

В каждом выпуске ведущая программы, веселая и заводная Гульчачак, вместе с симпатичными героями, в увлекательной игровой форме знакомит маленьких зрителей с новыми словами, культурой и традициями татарского народа. Важнейшими элементами программы являются интерактивные развивающие задания, которые вовлекают в тематические игры как детей в студии, так и малышей у телеэкранов, что способствует развитию речи, словарного запаса, а главное — интереса к изучению татарского языка и формированию основ поликультурной личности.

В телепередачах использованы новые развивающие образовательные технологии изучения татарского языка как средства общения. Хронометраж программы — 10 минут, что соответствует оптимальной продолжительности просмотра телепередачи, рекомендованной детскими специалистами. Программа подготовлена по заказу Министерства образования и науки Республики Татарстан при содействии Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

**Трансляция программы «Әкият илендә» по воскресеньям в 9:30 на телеканале ТНВ «Новый век»!**

После трансляции, телевизионную версию передачи «Әкият илендә», Вы можете увидеть или скачать на сайте Министерства образования и науки Республики Татарстан **mon.tatarstan.ru в разделе «Дошкольное образование».**

**Для обучения детей государственным языкам** разработаны три CD диска: музыкальные сказки на тат.яз - «Африка хикмәтләре», «Сертотмас үрдәк», «Бардым күлгә, салдым кармак...» и детские песни на тат.яз. – «Бииләр итек-читекләр» Луизы Батыр-Булгари; аудиозаписи татарских народных танцевальных мелодий «Шома бас» (29 мелодий); осуществлен перевод мультфильмов на татарский язык

## Перевод мультипликационных фильмов «Союзмультфильм» на татарский язык:

1. Крокодил Гена
2. Чебурашка
3. Шапокляк
4. Как львенок и черепаха пели песню
5. Винни-Пух
6. Винни-Пух идет в гости
7. Винни-Пух и день забот
8. Котенок по имени Гав № 1
9. Котенок по имени Гав № 2
10. Котенок по имени Гав № 3
11. Трое из Простоквашино
12. Каникулы в Простоквашино
13. Зима в Простоквашино
14. Кто сказал «Мяу»?
15. Золушка
16. Двенадцать месяцев
17. Малыш и Карлсон
18. Карлсон вернулся

## Анимационные сюжеты (до 3-х минут):

1. Әйдә дуслашыйк
2. Качышлы уйныйбыз
3. Шалкан экияте буенча
4. Безнең кунаклар
5. Тәмле кибетендә
6. Азат кунак чакыра
7. Карусельга сәяхәт
8. Уенчыклар үпкәләде
9. Күңелле уеннар
10. Акбай һәм Мияу маҗаралары
11. Уйный-уйный саныйбыз
12. Күңелле ял итәбез

## Аудиозаписи для детей дошкольного возраста:

1. Минем гаиләм
2. Минем туганнарым
3. Әйдәгез танышыйк
4. Минем дуслар
5. Әйе.Юк
6. Кунак килгән
7. Сөт. Чәй
8. Песине сыйла
9. Туган көн
10. Алия кунакка килгән
11. Уйныйбыз
12. Алсуга бүләк
13. Бүләкләр
14. Уйныйбыз да, саныйбыз да

## Создание мультипликационных фильмов на татарском языке:

1. Өч кыз
2. Алтын бөртекләр
3. Ике кыз
4. Төлке белән каз
5. Бүләк кемгә?
6. Шүрәле
7. Су анасы
8. Кәҗә белән сарык
9. Чукмар белән Тукмар
10. Куян кызы
11. Сертотмас үрдәк
12. Агачлар да авырый

# Туган телдә сөйләшәбез

Моңлы тел ул, нурлы тел – Туган тел.
Баш очында кояш булып тора гел.
Ф. Әмәк.

Без - татарлар өчен татар теле туган тел санала. Туган телдә яңгыраган сүзләрнең эмоциональ-эстетик буяуларының бик нечкә төсмерләре чагылышы балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен рухи байлык чыганагы булып тора. Без аны яшь буынга тапшырырга тиешбез.

Туган тел - сабыйларга аң-белем һәм тәрбия бирү өчен иң шифалы һәм рухландыргыч чишмә. Нәниләр белән эшләгәндә шушы чишмәнең – туган тел байлыгының ачылуы өчен тырышырга кирәк, чөнки тел һәм сүз яшәешнең бөтен өлкәләренә дә үтеп кергән һәм кеше тормышында зур роль уйный. Кешенең һәрбер шөгыле, һәрбер эше тел ярдәмендә башкарыла.

Безгә телгә сәләтлелек бүләк итеп бирелгән икән, аны нәтиҗәле итеп куллана белү кирәк. Бала туган телнең нечкәлекләрен никадәр тирәнрәк танып белсә, туган тел төсмерләре чагылышын шулкадәр яхшырак кабул итә, аның йөрәге дә сүзнең матурлыгын шулкадәр активрак аңлый, һәм ул сүзләр тылсымына да шулкадәр тизрәк төшенә. Сүзләр тылсымына өйрәнү кешегә тормышын уңай якка үзгәртү, башка кешеләр белән актив аралашу, аларга ярдәм итү, бик яхшы оратор, әңгәмәдәш булу мөмкинлеге бирә.

Туган телне үзләштергәндә, сөйләм үстергәндә сүзләр белән уйларга гына түгел, сүзләр турында уйлый белергә һәм балаларны да шуңа өйрәтергә кирәк. Тәрбияче үзе сүзләрнең тирән мәгънәгә, сокландыргыч, таң калдыргыч искиткеч бик зур көчкә ия булуын тоемлап, шуны балаларга төшендерә алса, аларның хисләрен, күңелен, фикерләрен, кичерешләрен яхшыртыр, тирәнәйтер. Туган телнең, сүзләрнең тылсымга ия мөмкинлекләрен үзләштерү һәм аңлау балаларга киләчәктә күңелгә хуш килгән эш белән шөгыльләнеп, үзләреннән һәрвакыт канәгать булып, бәхетле, шатлыклы тормышта яшәргә ярдәм итәр.

Туган тел могҗизалар тудыра ала. Сәламәтлек, бәхет, җан тынычлыгы, күтәренке күңел халәте безнең нәрсә уйлау, нәрсә сөйләү белән тыгыз бәйләнгән. Шуңа күрә туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү эшендә һәр тәрбияче бала күңеленә яраган ачкычны табып, аларның телнең матурлыгын тоюларына, сүзгә сак карауларына, аның сафлыгы турында кайгыртуларына ирешсен иде. Бу сүзләр буш сүзләр генә булып калмасын иде!

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»нда мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу - республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре. Әлеге проблемаларның бер өлеше “Туган телдә сөйләшәбез” өйрәтү-методик комплектлары ярдәмендә чишелә. Тәкъдим ителгән әсбап – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләмен үстерү буенча методик кулланма. Аның төп максаты ана телендә балаларның дөрес һәм яхшы телдән сөйләмен формалаштыру. Кече яшьтән үк баланың сөйләмен үстерү аның аралашу, танып белү, әхлакый һәм рухи юнәлешләр нигезен билгели.

Ул 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелгән һәм “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик әсбап балалар бакчасында беренче кече яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. “Туган телдә сөйләшәбез” дип исемләнгән методик комплект икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә хәзерлек төркемнәре өчен дә әзерләнә. Бу комплектның төп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

Беренче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерыла. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгенә алына.

## Балалар белән өйрәнегез!

**Кояш ,чык.**

Кояш чык,чык.чык
Синең җылың бик тансык
Чыксаң без сөенербез
Майлы ботка казанда.
Тәти кашык базарда.
Тәти кашык саф алтын,
Кирәкми безгә салкын.

**Бармак уены.**

Бу бармак бабай.
Бу бармак әби.
Бу бармак әти.
Бу бармак әни.
Бу бармак бәби аның
исеме Чәнти.

**Матрёшкалар.**

Без- матрёшкалар, матур курчаклар
Менә шундый ,менә шундый
Чип-чиста куллар.
Без- матрёшкалар, матур курчаклар.
Менә шундый, менә шундый
Кызыл иреннәр.
Без матрёшкалар, матур курчаклар.
Тып-тын итеп биибез, без
Шат күңеллеләр.

**Саф һава.**

Салкын саф һава.
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң
Битләр кызара.
Кар бөртекләре
Өстенә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

Ә.Бикчәнтәева.

**Саумы кояш!**

Саумы кояш!
Саумы һава!
Саумы иртә!
Саумы йомшак җил!
Саумы , Туган ил!

**Туп.**

Әминә елый үкереп
Тубым суга төште дип.
Чү, Әминә җылама,
Туп батмый ул елгада.

**Яз**

Тып-тып. Тып.тып.
Тып.тып
Тамчы тама талларга.
Талларымның бөреләре,
Куаныша шуларга.
Тып,тып,тып,тып
Тып-тып

**Яратам.**

Яратам мин өемне.
Әти белән әнине.
Абый белән апаны,
Бишектәге сеңлемне.